РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**Исполнительный комитет**
**Осинниковского сельского поселения**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы**
***Осинниковское авыл жирлеге***
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Молодежная , 9А, пос.Осинники, 422824
тел. (884377) 3-39-29 факс: (884377) 3-39-29
e-mail:adm@kama-tamagy.gov.tatarstan.ru
ИНН/КПП 1622004651/162201001

Молодежная урамы, 9А, п.Осинники, 422824,
тел. (884377) 3-39-29 факс: (884377) 3-39-29
e-mail:adm@kama-tamagy.gov.tatarstan.ru
ИНН/КПП 1622004651/162201001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 23 октябре № 22

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Осинники авыл җирлеге Башкарма комитетының 2015 елның 10 ноябрендәге 11 номерлы “2016-2020 елларга Кама Тамагы муниципаль районы Осинники авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү, энергетика нәтиҗәлелеген һәм юл куркынычсызлыгын арттыру” муниципаль программасын раслау турында” карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Осинники авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. “2016-2020 елларга Кама Тамагы муниципаль районы Осинники авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү, энергетика нәтиҗәлелеген һәм юл куркынычсызлыгын арттыру” муниципаль программасын раслау турында” 2015 елның 10 ноябрендәге 11 номерлы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Осинники авыл җирлеге башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.Программа атамасында “2016-2020” санын “2016-2024” санына алмаштырырга».

1.2.Программа паспортында:

а) “Программаны гамәлгә ашыру сроклары” юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| “Программаны тормышка ашыру сроклары | 2016-2024 еллар” |

б) “Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары” юлында:
беренче абзацта “1343,8” санын “3232,5” санына алмаштырырга;
алтынчы абзацта “2020 ел - 299,2” санын “2020 ел - 431,5” санына алмаштырырга;
җиденче – унынчы абзацларн белән тулыландырырга:
“2021 ел-433,8 мең сум;
2022 ел -436,5 мең сум;
2023 ел -440,8 мең сум;
2024 ел -445,3 мең сум”;
в) 2 пунктның егерме беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“2016-2024 еллар программасын тормышка ашыру сроклары”;
г) 4 пунктның беренче абзацында икенче тәкъдимне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“2016-2024 елларда планлаштырылган чыгымнарның гомуми суммасы -232,5 мең сум”;
д) 5 пунктның беренче абзацында алтынчы юлны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“2016-2024 елларга Осинники авыл җирлеге территориясендә урамнарны яктырту һәм энергияне сак тоту өлкәсендә озак сроклы максатчан программаны тормышка ашыруны контрольдә тоту.”.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кама Тамагы муниципаль районы Осинники авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (сәркәтибе) Чурбанова Оксана Владимировнага йөкләргә.

Җитәкче Сәгъдиев А. Х.